# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Олы Мәңгәр торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында

"28" ноябрь 2021 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 28 ноябрендә 09 сәгать 00 минутта, 2021 елның 28 ноябрендә 12 сәгать 00 минутта, 2021 елның 28 ноябрендә 15 сәгать 00 минутта узган этаплы җыеннар нәтиҗәләре белән «Сез 2022 елда Олы Мәңгәр авыл җирлеге Олы Мәңгәр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Олы Мәңгәр авылының Пролетарская һәм Татарстан урамнарында асфальт-бетон өслеген ремонтлау өчен төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;
- Олы Мәңгәр авылында балалар өчен уен мәйданчыгын сатып алу һәм урнаштыру.

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыенының беркетмәсе төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә **519** (биш йөз унтугыз) кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә катнашкан граҗданнар саны **296** (ике йөз туксан алты) кеше, бу **57,03 %** тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Риза» позициясе өчен халык җыенында катнашучы **296** (ике йөз туксан алты) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның **0** (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Олы Мәңгәр авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

"Сез 2022 елда Олы Мәңгәр авыл җирлеге Олы Мәңгәр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме

- Олы Мәңгәр авылының Пролетарская һәм Татарстан урамнарында асфальт-бетон өслеген ремонтлау өчен төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;
- Олы Мәңгәр авылында балалар өчен уен мәйданчыгын сатып алу һәм урнаштыру"

мәсьәләсен кабул ителгән дип санарга.

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Олы Мәңгәр авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Олы Мәңгәр авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Совет Большеменгерского сельского поселения
Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советы

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Мәңгәр авыл җирлеге башлыгы Тахавиев Ф.К.